КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 21 июль г.Казань № 876

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән расланган Яшәүләренең беренче өч елында балаларны махсус сөт туклану продуктлары һәм катнашмалар белән табиблар рецептлары буенча түләүсез тәэмин итүгә социаль ярдәм чараларын бирү кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балаларны табиблар рецептлары буенча туклану өчен махсус сөт продуктлары һәм катнашмалары белән түләүсез тәэмин итү һәм аны оештыру чыгымнарын финанслау тәртибе турында» 2009 ел, 31 декабрь, 933 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 7 июнь, 438 нче, 2010 ел, 24 август, 676 нчы, 2010 ел, 22 декабрь, 1094 нче, 2011 ел, 25 гыйнвар, 41 нче, 2012 ел, 24 октябрь, 901 нче, 2013 ел, 28 март, 211 нче, 2016 ел, 26 август, 594 нче, 2017 ел, 13 июль,

492 нче, 2017 ел, 24 август, 597 нче, 2017 ел, 20 ноябрь, 892 нче, 2019 ел, 6 декабрь, 1121 нче, 2020 ел, 15 октябрь, 929 нчы, 2023 ел, 04 февраль, 100 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Яшәүләренең беренче өч елында балаларны махсус сөт туклану продуктлары һәм катнашмалар белән табиблар рецептлары буенча түләүсез тәэмин итүгә социаль ярдәм чараларын бирү кысаларында Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы арасында мәгълүмат алмашу тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «(алга таба - тулы кыйммәтле туклану)» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү турында» 2019 ел, 3 декабрь, 1095 нче карарында билгеләнгән тәртиптә бирелә торган «Дару чаралары әйләнеше турында» 2010 елның 12 апрелендәге 61-ФЗ номерлы Федераль законның 55 статьясындагы 7 өлешендә каралган Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек ярдәмендә Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан җан башына уртача керем Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән артмаган, даруханә ассортиментының дару чараларын һәм башка товарларын сатып алуга түләүләр алучы булган гаиләләрдән булган өч яшьлек балаларга белешмәләр ала.»;

3 һәм 4 пунктлар үз көчләрен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин